Алга, белем иленә!



# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче лицей
«Фарватер» укучыларының нәфис басмасы

17 нче февраль, 2018 ел
№ 2



Әлеге санда

Укытучы - киләчәккә нигез салучы
(2 нче бит)

Лицей яңалыклары
(3 нче бит)

Туган тел
(4 нче бит)

Кызыклы мәгълүмат
(5, 6, 10 нчы битләр)

Илһам канатында
(7-9 нчы битләр)





# КИЛӘЧӘККӘ НИГЕЗ СЕЗ

Безгә һәрвакыт ял итәргә кушса да, үзенең ял иткәнен күргәнем юк. Ул безнең белән төрле чаралар оештыра. Кайчан ярдәм сорап килсәң дә, ул: “вакытым юк” яисә “ардым”, дип кире бормый. Игътибар белән тыңлый, аңлата, ярдәм итә. Шуңа аның янынннын кеше өзелми. Дәресләрдән соң да, кичке якта да лицейда күрергә була аны. Аның өчен иң мөһиме – лицей һәм без. Кайвакыт кызганып та куям үзен. Ул да бит арый, алҗыйдыр. Кайчан ял итәргә өлгерә икән соң ул? Һәркөн кочак – кочак дәфтәр тикшереп, журнал тутырып, ничә дәрескә планнар да язасы бар бит әле аның. Мөгаен, төне буе шуларны эшлидер. Ә иртән елмаеп укучылар каршына кереп баса да, гадәттәгечә, “Исәнмесез. Дәресне башлыйбыз…“ - дип яңа көнен башлап җибәрә. Шул минутларда ул чиксез бәхетледер кебек тоела миңа. Үз һөнәреңне яратып, хезмәтеңә күрә хөрмәтен дә тоеп яшәүдән дә зур бәхет бармы икән.





Тик тиздән аерылышу мизгелләре җитәсе генә күңелне тырный, моңсуландыра. Ләкин лицеебызны һәм укытучы апабыз – Гөлназ Рәисовнаны онытмыйча, аралашып торачагыбызга мин ышанам. Бу – табигый, чөнки ул безнең яклаучыбыз, киңәшчебез, тәрбиячебез.

Кадерле сыйныф җитәкчебез– Гөлназ Рәисовнаны «Ел укытучы-сы» конкурсында 1 нче урын алуы белән котлыйбыз. Аңа яңадан-яңа уңышлар телибез.

Киләчәктә бу дөньяда нинди генә биеклекләргә ирешсәк тә, уңышларыбызның башында укытучы торганын һәркем таныр.

Укытучылар – җирдә иң бөек кешеләр!

*Кәримова Ирина, 8Е*

# Укучылар көч сынаша

Гайнанова Аделинаны Россиякүләм рус әдәбияты олимпиадасында призер булуы белән тәбрик итәбез! Укытучысы Кофтункина Елена Валентин кызына зур рәхмәтебезне белдерәбез.






Ниһаять, лицеебыз тормышында елга бер генә була торган көтеп алынган “Минута славы” конкурсы да башланып китте. 31 нче гыйнвар көнне иң талантлы укучыларыбыз үзләренең сәләтләрен сәхнәдә күрсәтте. Быелгы конкурс номерларның төрлелеге белән аерылып торды. Алга таба да катнашучыларга зур уңышлар телибез!

1 нче февраль көнне хоккейчыларыбыз “Алтын алка” (“Золотая шайба”) Бөтенроссия ярышының шәһәр этабында катнашып, яхшы урыннар яуладылар!






6м сыйныфы укучысы—Булатов Данил “Иң яхшы уйнаучы” дигән исемгә лаек булды!





Февраль ае вакыйгаларга бай ай. 13-14 февраль көнне спорт залында тантаналы рәвештә Ватанны саклаучылар көненә багышланган чара үтте. Әлеге вакыйга укучыларыбыз өчен генә түгел, килгән кунаклар өчен дә бик күңелле булды.

5М, 6Г, 7М, 8Г сыйныф укучылары беренчелекне яуладылар.

*Инсафетдинов Эмиль, 8М*

# ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ

***И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!***
***Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.***

***Г. Тукай***

Берләшкән Милләтләр оешмасы (БМО) карары буенча 21 нче февраль – **ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ.**

Беренче мәртәбә ул 2000 нче елның 21 февралендә Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында тантаналы рәвештә билгеләп үтелде.

Җир йөзендә бүгенге көндә 6000 тел бар дип исәпләнә. Шулардан иң күп санлы кешеләр тарафыннан кулланыла торганы — кытай теле, бу телдә 1,2 млрд. кеше сөйләшә, инглиз телендә — 478 млн, хинди телендә — 437 млн, испан телендә — 392 млн, рус телендә — 284 млн, гарәп телендә — 225 млн, француз телендә 125 млн кеше сөйләшә.

Белгәнебезчә, дөньяда бик күп телләргә бетү куркынычы яный. Белгечләр якындагы йөзьеллыкта барлык телләрнең 95% ы яшәүдән туктар дип фараз итә. Мәсәлән, бер ел эчендә 10 тел юкка чыга дигән фикер бар. Телләрнең юкка чыгу процессы аеруча Бразилиядә көчле.

Тел юкка чыктымы, шул телдә сөйләшкән халык та юкка чыга дигән сүз, чөнки ул инде башка телдә сөйләшә башлый, шул телдәге мәгълүматны үзләштерә, ә аның үз бабаларының йөзләрчә ел үсеп-формалашып килгән мәдәнияты тел белән бергә юкка чыга. Шуңа күрә туган телебезне сакларга, туган телебездә

Туган тел үзем өчен, башка тел көнем өчен.

Усал тел кыш кебек, яхшы тел яз кебек.

Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр.

Тел – күңел көзгесе.

*Маслов Олег, 9Е*

# ЭТ ЕЛЫН КАРШЫ АЛДЫК



**2018 ел Көнчыгыш календаре буенча САРЫ ҖИР ЭТЕ елы. Ә сез этләр турынданиләр беләсез? Тестны чишәр өчен эт токымнарын гына түгел, әдәбиятны һәм татар театрын да белергә кирәк булачак.**

**"Авыл эте Акбай"дагы Әсхәт Хисмәт нинди токымлы эт булып уйный?**

* Овчарка
* Урам эте
* Акбай

**Комиссар Рекс нинди токымлы эт?**

* Австралия овчаркасы
* Немец овчаркасы
* Көнчыгыш Себер лайкасы

Нияз Акмал хикәясендә хуҗасына: "Ким, гырлама!" дип кычкырган Марта нинди токымлы?

* Мопс
* Овчарка
*Лабрадор

**"Ко мне, Мухтар!" фильмында Никулинның эте нинди токымлы?**

* Көнчыгыш Европа овчаркасы
* Төрекмән овчаркасы
* Бурзай

**"Маска" фильмындагы этнең нинди токымлы икәнен хәтта эт сөючеләр дә танымаган, диләр.**

* Бульмастиф
* Ягдтерьер
* Джек рассел терьер

"Авыл эте Акбай"дагы Шамкай нинди токымлы?

* Дог
* Эрәшит
* Бульдог

"Авыл эте Акбайда" чарли токымлы эт ролендә кем уйный?

* Люция Хәмитова
* Илсөя Төхвәтуллина
* Лилия Мәхмүтова



Хатиконы яратасызмы? Ә аның нинди токымлы эт икәнен беләсезме?

* Япон лайкасы
* Корги
* Акита ину



*Матвейчева Анастасия, 5А*

# ИҢ ЗУР КАР БӨРТЕГЕ

Дөньядаиң зур кар бөртеге 1887 елда Американың Монтана штатында табылган. Кар бөртегенең киңлеге 1 см артмавын истә тотканда, ул, чынлап та, зур кар бөртеге булып саналырга лаеклы. Аның киңлеге—38, ә калынлыгы 20 см булган.

# КЫЗЫЛ ДӨНЬЯ

Гадәттә, без күреп өйрәнгән ак кар төрле төстә булырга мөмкин. Һавада тузан, ком яки башка катнашма булганда, өстән коңгырт, алсу, кызыл кар да яварга мөмкин. 2007 елда Сүриядә—кызгылт-сары, ә 2010 елда Краснодарда алсу төстәге кар яуган.

# ЧЫРШЫ УЕЧЫКЛАРЫ

Урта гасырларда ук европалылар Раштуа алдыннан өйләренә яшел чыршы ботакларын алып кайта торган булганнвр. Башлангыч чорда аны бары тик тәм-томнар белән генә бизәгәннәр. Ә XVII гасырда чыршы өчен махсус уенчыклар ясый башлаганнар. Ләкин без иялəшкән үтәкүренмәле һәм төсле пыяладан эшләнгән чыршы шарларын бары тик XIX гасырда Тюрингиядә әзерли башлаганнар.

# МАНДАРИН ЯРАТСАҢ

Мандарин безнең өчен Яңа ел символы. Аның туган ягы—Кытай. Танжело, натсумкан, унишу, клементина, сацумский—болары мандарин сортлары. Иң татлысы—сацумский мандарин. Ул япониядәге бер урын исеме белән шулай аталган. Төшсез мандарин яратучыарга унишу дигән сорт хуш килер.

*Миндубаева Альбина, 5А*

## ХЫЯЛЫМДА ОЧАМ

Менә күкләргә очучы оста,
Төшә җирләргә канат шәүләсе.
Елгалар, күлләр, тау кала аста,
Кала өйләре, кала гаиләсе...

Очучы өчен батырлык кирәк,
Белемле булу, куркусыз йөрәк.
Очучы булу – бердән бер теләк,
Әти-әнигә киләчәк терәк.

Ак канатлы матур самолетлар
Төшләремә керә еш кына.
Кул болгыйлар кебек минем дуслар,
Күңел һаман күккә ашкына.

Сыртланова белән Гагариннан
Балачагымнан үрнәкләр алам.
Бу һөнәрнең җаваплы булуын,
Аңласам да, кире уйламам.

Ачык күкләрдә рәхәт очуым!
Җан рәхәте очып йөрүем!
Балачактан ук хыяллануым,
Бар теләгем – очасы килүем.

Шуңа бүгеннән хыялга таба
Атлыйм әкренләп һәр адым алга.
Дәресләрдә мин тырышып укыйм.
Белем кирәген бик яхшы аңлыйм.

## ТУГАН ИЛГӘ СОКЛАНУ

Һәр фасылның үз яме,
Һәрбер айның үз гаме.
Җәйнең үз матурлыгы,
Көзнең күп уңышлары.

Кышын чана шуабыз,
Елгаларда туңа боз.
Язын болында, кырда
Күбәләкләр куабыз.

Туган илгә сокланам,
Табигатьтә чуалам.
Үз җиремне яратудан
Шатлыгымнан куанам.



*Инсафетдинов Эмиль, 8М*

## ИҢ КҮҢЕЛЛЕ БӘЙРӘМ

Күптән түгел генә иң күңелле бәйрәмнәрнең берсе – Яңа ел үтте. Яңа ел – иң күңелле һәм иң борынгы бәйрәмнәрнең берсе. Безнең илдә Яңа ел 1 нче гыйнвардан башлана. Әмма төрле илләр бу бәйрәмне үз календарьлары буенча билгеләп үтәләр. Борынгы греклар Яңа елны 21 көннән соң тулган ай белән башлаганнар. Христиан динле илләрнең күбесендә Яңа ел гыйнвардан башлана. Кытайда Яңа ел ике тапкыр бәйрәм ителә. Беренче тапкыр 1 нче гыйнвар булса, икенче тапкыр үзләренең ай календаре буенча, 23 нче гыйнвардан алып 19 нчы февральгә кадәр булган көннәрнең берсендә. Корея исә Яңа елгы, безнең кебек, гыйнварның беренче өч көнендә бәйрәм итә.

## БЕРГӘЛӘП КӨЛЕП АЛЫЙК



Булатның балачагы авыр булды: ул берүзе интернетта үсте.

Марат мәктәптән өенә кайткач: «Физикадан - «2», татар теленнән - «2», химиядән - «2», җырдан - «5»., - ди.

Әтисе каешын алып:

- Син шул билгеләрең белән җырлап та йөрисеңме әле? - ди.

- Әти, бүген укытучы апа сорау биргәч, мин беренче булып кул күтәрдем!

- Ай, рәхмәт, улым!. Ә укытучы нәрсә сорады?

- «Мәсьәләне кайсыгыз чишә алмады?» - диде.

- Хәлләр шәптән түгел - этем югалды.

- Гәзиткә белдерү биреп кара.

- Файдасыз. Ул бит укый белми...





## МОГҖИЗАЛЫ КЫШ

Үзенең могҗизаларын ияртеп, көткән кыш та килеп җитте. Бөтен дөнья аклыкка, сафлыкка күмелде.

Өр-яңа җирләрне үзләштергәндәй, беркем дә аяк басмаган яңа яуган карга эз салып баруы бик күңелле.

Яңа яуган кар өстендә аерым бер тормыш. Әнә зур эзләр янында кечкенә эзләр. Бәлкем, әни белән бала бакчага барганда калган эзләрдер… Минем арттан да мәктәпкә барган эзләр төшеп кала. Мондый матурлык бары кыш көне генә була ала.

Укулар беткәннән соң, рәхәтләнеп урамда уйнау ни тора бит! Кар йомарлап атышу, җепшек кардан Кар бабай һәм Кар кызы, тагы әллә нинди фигуралар ясау дисеңме – берсе дә калмый. Тимераякларга, чаналарга, чаңгыларга да чират җитә. Болар барысы да кыш көне генә була торган күренешләр. Шуңа күрә без кышны яратабыз.

## АП-АК КЫШНЫ КӨТӘБЕЗ



Ап-ак, ап-ак кар ява,
Күңел кылын ярсыта.
Кыш бабайдан һәрбер бала
Яхшы бүләкләр ала.

Кыш, кыш, кыш килә,
Җиһан акка күмелә.
Беренче кар яву белән
Безне карлы тау көтә.

Көтеп алган кыш җитте,
Тау шуарга чабабыз.
Компьютер-планшетлардан
Аерылып торабыз.

*Миндубаева Альбина, 5А*

# Бәйге!



### Кагыйдә

Рәсемдәге буш урынга кызыклы комментарий уйлап тап һәм җавабыңны 212 нче кабинетка хәбәр ит.

Дуслар, иң кызык комментарий авторын бүләк көтә!

## Укучыларыбыз иҗаты



Хадиев Адель, 3Г



Мәрданова Гүзәл, 5Г



Салахова Руфинә, 4Г



Абдюшев Кирил, 4Г



Рачаков Сергей, 4Г

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы «78 нче лицей «Фарватер»

(Ю.Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс 268-58-61.

E-mail: school_7878@mail.ru

Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин: https://edu.tatar. ru/priv/school78.htm/ page813169. htm

**Мөхәррир:** *Инсафетдинов Эмиль,*
*Маслов Олег.,*
*Миндубаева Альбина*
*Матвейчева Анастасия*
***Консультант:*** *Фәйзуллина Рәзилә Яудәт кызы.*